МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

от 29.11.2013

№ 389

г.Казань

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган һәм шулай ук вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

«Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтләре турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17.1 маддәләренә ярашлы рәвештә һәм Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен һәм вазыйфаны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-701 номерлы Указын, «Вазыйфаны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 елның 22 апрелендәге УП-329 номерлы Указын тормышка ашыру максатында **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган һәм шулай ук вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга (алга таба - Исемлек).

2. Кадрлар бүлегенә:

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

җиде көн эчендә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәтләре һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә җиткерергә;

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының түбәндәге боерыклары үз көчләрен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге турында» **2010 елның 31августындагы 254нче**;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге турында» 2010 елның 31 августындагы 254нче боерыгына үзгәрешләр кертү турында» **2011 елның 22 февралендәге 29нчы**;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәтләре вазыйфалары исемлеге турында» 2010 елның 31 августындагы 254нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен һәм вазыйфаны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының исемлегенә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге турында» 2011 елның 31августындагы 254нче боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 22 февралендәге 29нчы боерыгы үз көчен югалтуы турында» **2012 елның 15 февралендәге 47нче**;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге турында» 2010 елның 31 августындагы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен һәм вазыйфаны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» **2013 елның 25 февралендәге 52нче**.

4. 2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Министр** **М.Р.Шагиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы боерыгы
белән расланган
«29» ноябрь 2013 ел № 389

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган һәм шулай ук вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары

Исемлеге

1. Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары
2. Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары
3. Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү департаменты башлыгы
4. Эшләр белән идарәче
5. Министр ярдәмчесе
6. Фаразлау һәм стратегик үсеш идарәсе башлыгы
7.Административ реформа мәсьәләләре идарәсе башлыгы
8. Территориаль үсеш идарәсе башлыгы
9. Инвестицияле һәм инновацияле эшчәнлек идарәсе башлыгы
10. Оештыру идарәсе башлыгы
11. Юридик бүлек башлыгы
12. Финанс исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы
13. Кадрлар бүлеге башлыгы
14. Дәүләт мәгълүмати ресурслар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлеге башлыгы
15. Режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр секторы мөдире
16. Юридик бүлек башлыгы урынбасары
17. Финанс исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы урынбасары
18. Дәүләт мәгълүмати ресурслар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлеге башлыгы урынбасары
19. Эшкуарлыкны үстерү департаменты башлыгы урынбасары
20. Макроикътисадый фаразлау бүлеге башлыгы
21. Стратегик үсеш бүлеге башлыгы
22. Индикатив идарә бүлеге башлыгы
23. Икътисад тармаклары һәм социаль өлкә үсеше бүлеге башлыгы
24. Инвестицияле эшчәнлек бүлеге башлыгы
25. Инвестицияле проектларга дәүләт ярдәме күрсәтү бүлеге башлыгы
26. Инновацияле эшчәнлек бүлеге башлыгы
27. Конкуренцияне үстерү бүлеге башлыгы

28. Муниципаль берәмлекләр үсеше бүлеге башлыгы
29. Инфраструктураны үстерү бүлеге башлыгы
30. Максатчан программалар бүлеге башлыгы
31. Дәүләт идарәсен камилләштерү бүлеге башлыгы
32. Лицензияләү бүлеге башлыгы
33. Икътисадый анализ  һәм финанс продуктлары бүлеге башлыгы
34. Кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлеге башлыгы
35. Финанс-хокукый консультацияләр бүлеге башлыгы
36. Оештыру эшләре бүлеге башлыгы
37. Эшләр башкару бүлеге башлыгы
38. Мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы
39. Административ-хуҗалык бүлеге башлыгы
40. Икътисад өчен кадрлар әзерләү һәм көйләү тәэсирен бәяләү секторы мөдире
41. Макроикътисадый фаразлау бүлеге башлыгы урынбасары
42. Инновацияле эшчәнлек бүлеге башлыгы урынбасары
43. Муниципаль берәмлекләр үсеше бүлеге башлыгы урынбасары
44. Максатчан программалар бүлеге башлыгы урынбасары
45. Инвестицияле проектларга дәүләт ярдәме күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе
46. Инвестицияле проектларга дәүләт ярдәме күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы консультанты
47. Конкуренцияне үстерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты
48. Конкуренцияне үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече
49. Инфраструктураны үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе
50. Инфраструктураны үстерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты
51. Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе
52. Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты
53. Икътисадый анализ  һәм финанс продуктлары бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе
54. Икътисадый анализ  һәм финанс продуктлары бүлегенең әйдәп баручы консультанты
55. Икътисадый анализ  һәм финанс продуктлары бүлегенең әйдәп баручы белгече
56. Кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече
57. Кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече
58. Финанс-хокукый консультацияләр бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе
59. Финанс-хокукый консультацияләр бүлегенең әйдәп баручы консультанты.